КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1246

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче; 2018 ел, 27 март, 176 нчы; 2018 ел, 10 май, 343 нче; 2018 ел, 29 август, 735 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1198 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 12 нче; 2019 ел, 13 февраль, 102 нче; 2019 ел, 6 июнь, 474 нче; 2019 ел, 31 октябрь, 974 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыгaнаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 382 761 498,11 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);<br>2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);<br>2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);<br>2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);<br>2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);<br>2019 ел – 61 936 507,78 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 17 590 942,7 мең сум);<br>2020 ел – 51 189 172,9 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 906 072,3 мең сум);<br>2021 ел – 50 325 411,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 595 898,5 мең сум);<br>2022 ел – 647 953,0 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 481 224,7 мең сум).<br>2023 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 382 761 498,11 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);

2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);

2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);

2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);

2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);

2019 ел – 61 936 507,78 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 17 590 942,7 мең сум);

2020 ел – 51 189 172,9 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 906 072,3 мең сум);

2021 ел – 50 325 411,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 13 595 898,5 мең сум);

2022 ел – 647 953,0 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 481 224,7 мең сум).

2023 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга мәктәпкәчә белем бирүне (инклюзив белем бирүне кертеп), үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 52 901 905,02 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 5 207 196,08 мең сум;<br>2015 ел – 5 613 039,5 мең сум;<br>2016 ел – 5 944 694,4 мең сум;<br>2017 ел – 5 872 878,8 мең сум;<br>2018 ел – 7 541 911,74 мең сум;<br>2019 ел – 7 633 318,5 мең сум;<br>2020 ел – 7 554 426,6 мең сум;<br>2021 ел – 7 534 439,4 мең сум.<br>2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2020 елда шәхси мәктәпкәчә оешмаларда 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен төзелгән мәктәпкәчә төркемнәр санын 14 берәмлеккә кадәр арттыру;

2020 елда шәхси мәктәпкәчә оешмаларда төзелгән мәктәпкәчә төркемнәрдә 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен урыннар санын 162 берәмлеккә кадәр арттыру.»;

2 бүлекнең 6 нчы бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«6. Дәүләтнеке булмаган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары челтәрен үстерү (шул исәптән Россия Федерациясе субъектларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда (дәүләт һәм муниципаль оешмалардан тыш) һәм мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары (шул исәптән адаптацияләнгән пограммалар) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләрдә 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен теләсә нинди юнәлештәге өстәмә урыннар (төркемнәр) булдыру чараларын тормышка ашыру һәм «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында балаларны караштырып тору һәм карау)**

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итүгә дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмалары тарафыннан билгеле бер өлеш кертә. Республика мәктәпкәчә белем бирүнең дәүләтнеке булмаган секторы 2011 елдан яңа мәктәпкәчә урыннар булдыру буенча «Бәләкәч» – «Малыш» масштаблы республика проектын тормышка ашыру чорында үсеш алды. 2010 – 2015 елларга «Киләчәк» – «Будущее» Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясен тормышка ашыру кысаларында 2011 елда 10 шәхси балалар бакчасы мәктәпкәчә төркемнәр булдыру проектларын гамәлгә ашыру өчен грантлар алды.

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы дәүләтнеке булмаган оешмалар челтәре актив үсә. 2019 ел башына Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең төп мәгариф программаларын тормышка ашыручы 28 дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмасы эшли: 21 шәхси балалар бакчасы, мәктәпкәчә төркемнәр белән 7 мәктәп. Шулай ук мәктәпкәчә белем бирү һәм балаларны караштырып тору һәм карау хезмәтләре белән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына лицензиясе булган 6 индивидуаль эшмәкәр шөгыльләнә. Дәүләтнеке булмаган оешмаларда мәктәпкәчә яшьтәге 3,5 меңгә якын бала тәрбияләнә.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә норматив чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү рәвешендә дәүләтнеке булмаган мәгариф оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафынна мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 март, 132 нче карары белән расланган.

Татарстан Республикасы бюджетыннан Шәхси белем бирү оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә субсидияләр бирү төп гомуми белем бирү

программаларын финанслау өлешендә дәүләт һәм шәхси белем бирү оешмаларын тигезләштерде.

2019 елда субсидияләр 15 шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмасына, мәктәпкәчә төркемнәр эшли торган 7 гомуми белем бирү оешмасына, мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы 6 индивидуаль эшмәкәргә бирелә. Дәүләтнеке булмаган мәктәпкәчә оешмаларга бирелә торган субсидияләрнең гомуми күләме 2012 елда 8,5 миллионнан 2018 елда 110 миллионга кадәр артты.

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында 2020 елдан Россия Федерациясе субъектларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда (дәүләт һәм муниципаль оешмалардан тыш) һәм мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары (шул исәптән адаптацияләнгән пограммалар) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләрдә 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен өстәмә урыннар (төркемнәр) булдыру чараларын тормышка ашыру һәм балаларны караштырып тору һәм карау планлаштырыла.

Чараның максаты – шәхси мәктәпкәчә оешмаларда мәктәпкәчә төркемнәр булдыру.

Чараны тормышка ашыру өчен Россия Федерациясе субъектларының «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү – 3 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын булдыру» федераль проектының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү карала.

Бу чара кысаларында 2020 елда шәхси мәктәпкәчә оешмаларда 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен 162 урынга исәпләнгән 14 мәктәпкәчә төркем төзү планлаштырыла.»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Ярдәмче программа чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 52 901 905,02 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 5 207 196,08 мең сум;
2015 ел – 5 613 039,5 мең сум;
2016 ел – 5 944 694,4 мең сум;
2017 ел – 5 872 878,8 мең сум;
2018 ел – 7 541 911,74 мең сум;
2019 ел – 7 633 318,5 мең сум;
2020 ел – 7 554 426,6 мең сум;
2021 ел – 7 534 439,4 мең сум.

2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлекнең таблицасына түбәндәге эчтәлекле 9 – 10 нчы пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «9. | шәхси мәктәпкәчә оешмаларда 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен булдырылган мәктәпкәчә төркемнәр саны | бер-рәм-лек | - | - | - | - | - | - | 14 | | | | |
| 10. | шәхси мәктәпкәчә оешмаларда төзелгән мәктәпкәчә төркем-нәрдә 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен урыннар саны | бер-рәм-лек | - | - | - | - | - | - | 162»; | | | | |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга гомуми белем бирүне (инклюзив белем бирүне кертеп) үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 159 107 970,44 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;<br>2015 ел – 18 902 517,8 мең сум;<br>2016 ел – 18 161 160,9 мең сум;<br>2017 ел – 18 684 936,6 мең сум;<br>2018 ел – 20 796 481,8 мең сум;<br>2019 ел – 22 165 602,5 мең сум;<br>2020 ел – 21 646 441,9 мең сум;<br>2021 ел – 21 397 019,3 мең сум;<br>2022 ел – 148 218,0 мең сум.<br>2023 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

Ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлында:

утыз сигезенче абзацта «0,01» саннарын «0,1622» саннарына алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«2022 ел ахырына бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре 100 процентка кадәр бирелгән, авыл торак пунктларына (эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга, 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә) күчеп килгән укытучыларның өлешен арттыру»;

2 бүлектә:

28 бүлекчәдә:

бүлекчә исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Заманча мәктәп» төбәк проекты чараларын тормышка ашыру (шул исәптән авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар юнәлешләрнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту) чаралары; гомуми белем бирү эшчәнлеген бары тик адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы оешмаларда матди-техник базаны яңарту буенча чаралар)»;

дүртенче – бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар юнәлешләрнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту);

гомуми белем бирү эшчәнлеген бары тик җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы оешмаларда матди-техник базаны яңарту.»;

28.1 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«28.1. «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар юнәлешләрнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту) буенча чаралар**

«2019 елда Татарстан Республикасында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар юнәлешләрнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту) чарасы кысаларында авыл районнарының 97 мәктәбе базасында цифрлы һәм гуманитар юнәлештәге белем бирү үзәкләре төзеләчәк, 2020 елда – 139 авыл мәктәбе базасында, 2021 елда – 214 авыл мәктәбе базасында, 2022 елда – 300 авыл мәктәбе базасында, 2023 елда – 400 авыл мәктәбе базасында, 2024 елда 500 авыл мәктәбе (арта бара торган йомгак белән).

Үзәкләрне җиһазландыру өчен укыту чаралары сатып алыначак (бигрәк тә «Технология», «Информатика», «Тормыш иминлеге нигезләре» дигән предметлар өлкәләре, дәрестән тыш эшчәнлек буенча).

2024 елга авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан 500 гомуми белем бирү оешмасы цифрлы һәм гуманитар юнәлешләрдәге төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен үзенең матди-техник базасын яңартачак.»;

28.2 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«28.2. «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында гомуми белем бирү эшчәнлеген бары тик адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы оешмаларда матди-техник базаны яңарту чаралары**

Гомуми белем бирү эшчәнлеген бары тик адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы оешмаларда матди-техник базаны яңарту чаралары кысаларында 2024 елга бары тик җайлаштырылган гомуми белем бирү программалары буенча гына белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы 39 оешмада матди-техник база яңартылачак: «Технология» предмет өлкәсе буенча хезмәт остаханәләре өчен җиһазлар, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга өстәмә белем бирү өчен педагог-психолог, укытучы-дефектолог, укытучы-логопед кабинетлары өчен җиһазлар сатып алыначак. Дистанцион укыту программаларын тормышка ашыру өчен шартлар тудырылачак.

2019 елда Татарстан Республикасының 17 мәгариф оешмасында, 2020 елда – 19 мәктәптә, 2021 елда – 21 мәктәптә, 2022 елда – 23 мәктәптә, 2023 елда – 28 мәктәптә, 2024 елда 39 мәктәптә яңадан җиһазландыру үткәреләчәк (арта бара торган нәтиҗә белән).»;

29 бүлекчәдә:

өченче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2024 елга балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) кимендә 162 мең психологик-педагогик, методик һәм консультацион ярдәм күрсәтеләчәк. Шулай ук ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны үз гаиләләренә тәрбиягә алырга теләүче гражданнарга ярдәм күрсәтеләчәк.

2019 елда Татарстан Республикасының 7 оешмасы консультация үзәкләре челтәрен булдыру буенча инновацион проектларны тормышка ашыра (өстәмә һөнәри белем бирүче «Менеджмент академиясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы, «Егоза» мәгариф үзәге» коммерциягә карамаган автоном гомуми белем бирү оешмасы, Яр Чаллы шәһәренең «Балкыш» 95 нче тәрбияләнүчеләрне үстерүнең сәнгати-эстетик юнәлеше буенча өстенлекле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы гомуми үсештерү төрендәге балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәренең катнаш төрдәге 12 нче «Гусельки» балалар бакчасы, Яр Чаллы шәһәренең катнаш төрдәге 105 нче «Дюймовочка» балалар бакчасы, Казан шәһәре Мәскәү районының тәрбия бирү һәм укыту татар телендә алып барыла торган катнаш төрдәге 403 нче балалар бакчасы, Казан шәһәре Яңа Савин районының катнаш төрдәге 151 нче балалар бакчасы).

2020 елда балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) психологик-педагогик, методик һәм консультацион ярдәм күрсәтүгә, шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны үз гаиләләренә тәрбиягә алырга теләүче гражданнарга юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыру «Егоза» мәгариф үзәгендә, психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен «Росток психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесендә һәм «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм күрсәтү, Казан шәһәренең алыштыручы гаиләләрен әзерләү һәм алып бару үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә дәвам итәчәк.»;

30 бүлекчәнең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проекты кысаларында заманча цифрлы белем бирү мохите булдыруны тәэмин итү максатларында, 2019 елда Татарстан Республикасында 32 белем бирү оешмасында (15 гомуми белем бирү оешмасы, 17 урта һөнәри белем бирү оешмасы) цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен гамәлгә кертү башланачак. 2020 елда әлеге чара 78 белем бирү оешмасы ярдәме белән дәвам итәчәк.

31 бүлекчәнең унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 – 2022 елларда федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү өчен Россия Федерациясе субъектларын сайлап алуда Татарстан Республикасының катнашуы йомгаклары буенча 2020 елда Казан (Идел буе) федераль университетының структур бүлекчәсе һәм Татарстан Республикасы педагогларының һөнәри осталыгын һәм квалификацияләрен бәяләү үзәге буларак Казан шәһәре, Социалистик урамы, 5 нче йорт (4 нче кат) адресы буенча дәүләт автоном учреждениесе формасындагы аерым юридик зат сыйфатында һөнәри осталыкны өзлексез күтәрү үзәген төзү планлаштырыла. 2022 елда өстәмә һөнәри белем бирүче «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең структур бүлекчәсе буларак һөнәри осталыкны өзлексез күтәрү үзәге оештырылачак.»;

түбәндәге эчтәлекле 32 бүлекчә өстәргә:

**«32. Авыл торак пунктларына йә эшчеләр поселокларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга йә 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченгән) укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру чаралары**

Татарстан Республикасында бүгенге көндә авыл җирендә кадрларга кытлык күзәтелә. Муниципаль районнарның (50 меңгә кадәр халкы булган шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән мәгълүмат буенча, Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә 100дән артык вакантлы вазыйфа формалаштырылган.

Вакантлы вазыйфалар исемлеген әзерләгәндә Татарстан Республикасы торак пунктларының демографик һәм социаль-икътисадый перспективалары исәпкә алынды. Гомуми белем бирү оешмаларында әлеге ихтыяҗны пенсия алды һәм пенсия яшендәге педагоглар тулыландыра.

Авыл торак пунктларына (эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга, 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә) эшкә килгән укытучыларга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру югары сыйфатлы белем бирүне тәэмин итәргә һәм квалификацияле укытучыларны җәлеп итү юлы белән авыл мәктәпләрендә кадрлар кытлыгын киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Куелган максатка ирешү авыл торак пунктларына йә эшчеләр поселокларына (эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга, 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә) эшкә күченгән укытучыга 1 млн.сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре бүлеп бирү аша планлаштырыла.

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында авыл торак пунктларына (эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга, 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә) эшкә күчкән укытучыларга бер тапкыр бирелә торган 34компенсация түләүләре каралган, шул исәптән 2020 елда – 13, 2021 елда – 11, 2022 елда – 10.»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаның чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 159 107 970,44 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;
2015 ел – 18 902 517,8 мең сум;
2016 ел – 18 161 160,9 мең сум;
2017 ел – 18 684 936,6 мең сум;
2018 ел – 20 796 481,8 мең сум;
2019 ел – 22 165 602,5 мең сум;
2020 ел – 21 646 441,9 мең сум;
2021 ел – 21 397 019,3 мең сум;
2022 ел – 148 218,0 мең сум.

2023 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлекнең таблицасында:

34 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «34. | Цифрлы, табигый-фәнни һәм гуманитар юнәлешләрдәге төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары белән җәлеп ителгән укучылар саны, мең кеше | - | - | - | - | - | 26,568 | 38,452 | 55,231 | 83,408 | 95,0 | 100,0 | -»; |

37 – 38 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «37. | Балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә), шулай ук ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны үз гаиләләренә тәрбиягә алырга теләүче гражданнарга психологик-педагогик, методик һәм консультатив ярдәм күрсәтү хезмәтләре саны, шул исәптән коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итеп, 2019 елдан арта бара торган йомгак белән, млн. берәмлек | - | - | - | - | - | 0,1202 | 0,1622 | 0,1622 | 0,1622 | 0,1622 | 0,1622 | - |
| 38. | Психологик-педагогик, методик һәм консультатив ярдәм күрсәтү сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми санында аларның сыйфатын уңай бәяләгән гражданнар өлеше, процент | - | - | - | - | - | 0 | 55 | 60 | 65 | 75 | 85 | -»; |

47 – 48 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «47. | Һөнәри квалифи-ацияне ирекле бәйсез бәяләүне узган педагог хезмәткәрләре өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | 0,8 | 1,4 | 10 | 10 | 10 | - |
| 48. | Россия Федерациясе субъектында уку предметларын (предмет өлкәләрен) укыту концепцияләрен исәпкә алып, гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль берәмлекләр өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | 1,1765 | 1,1765 | 1,1765 | 1,1765 | 1,1765 | - »; |

түбәндәге эчтәлекле 52 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «52. | Авыл торак пунктларына (эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга, 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә) эшкә күченгән, бер тапкыр | - | - | - | - | - | - | 37 | 70 | 100 | | | -»; |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирелә торган компенсация түләүләре бирелгән укытучылар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга өстәмә белем бирүне (инвалид балаларга белем бирүне кертеп) үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 3 406 789,11 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 139 168,88 мең сум;<br>2015 ел – 388 317,60 мең сум;<br>2016 ел – 529 023,0 мең сум;<br>2017 ел – 487 193,9 мең сум;<br>2018 ел – 522 533,83 мең сум;<br>2019 ел – 300 651,0 мең сум;<br>2020 ел – 653 267,0 мең сум;<br>2021 ел – 368 123,6 мең сум;<br>2022 ел – 18 510,3 мең сум.<br>2023 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында «3,4» саннарын «18» саннарына алыштырырга;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 3 406 789,11 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 139 168,88 мең сум;

2015 ел – 388 317,60 мең сум;
2016 ел – 529 023,0 мең сум;
2017 ел – 487 193,9 мең сум;
2018 ел – 522 533,83 мең сум;
2019 ел – 300 651,0 мең сум;
2020 ел – 653 267,0 мең сум;
2021 ел – 368 123,6 мең сум;
2022 ел – 18 510,3 мең сум.

2023 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлегендәге таблицаның 28 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «28. | «Кванториум» балалар технопаркларының («Кванториум» мобиль технопаркларының) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе технологик үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган табигый-фәнни һәм техник юнәлешле өстәмә гомуми белем бирү эшчәнлеге белән җәлеп ителгән балалар өлеше, мең кеше | - | - | - | - | - | 8 | 11 | 18 | - | - | - | - »; |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга һөнәр белеме һәм югары уку йортларын тәмамлаганнан соң белем бирүне үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

Ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 66 978 269,79 мең сум, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 4 500 128,27 мең сум;<br>2015 ел – 4 772 185,2 мең сум;<br>2016 ел – 4 939 069,8 мең сум;<br>2017 ел – 5 797 077,8 мең сум;<br>2018 ел – 20 004 491,14 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2019 ел – 13 518 632,18 мең сум;<br>2020 ел – 6 719 735,1 мең сум;<br>2021 ел – 6 726 950,3 мең сум.<br>2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлының кырык дүртенче абзацында «5» санын «44» саннарына алыштырырга;

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 66 978 269,79 мең сум, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 4 500 128,27 мең сум;
2015 ел – 4 772 185,2 мең сум;
2016 ел – 4 939 069,8 мең сум;
2017 ел – 5 797 077,8 мең сум;
2018 ел – 20 004 491,14 мең сум;
2019 ел – 13 518 632,18 мең сум;
2020 ел – 6 719 735,1 мең сум;
2021 ел – 6 726 950,3 мең сум.

2022 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлекнең таблицасындагы 65 – 68 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «65. | Йомгаклау аттестациясе демонстрацион имтихан формасында үткәрелә торган урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның өлеше, процент | - | - | - | - | - | 6,86 | 20 | 30 | 40 | 45 | 50 | - |
| 66. | Демонстрацион имтихан формасын кулланып аттестация үткән урта һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы | - | - | - | - | - | 9,64 | 6 | 8 | 13 | 18 | 25 | - |

| | | | | | | | | | | | | |
